| ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 03 2022 г. № 94

Федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб төзү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясенең 2021 елның 15 ноябрендәге 1026 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) (алга таба текст буенча - муниципаль штаб) төзергә һәм муниципаль штаб составын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| | **Штаб җитәкчесе:** | |
| 1. | Нотфуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы; |
| | **Штаб җитәкчесе урынбасарлары:** | |
| 2. | Сабирҗанов Н.Н. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары; |
| 3. | Хәйретдинов А. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе; |
| | **Штаб секретаре:** | |
| 4. | Гарифҗанов Р.М. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы; |
| | **Штаб әгъзалары:** | |
| 5. | Галимуллин И. С. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| 6. | Гайнетдинов И. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| 7. | Нәбиуллин Ф. Р. | Балтач муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| 8. | Фатыхов Р. С. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты юридик бүлеге башлыгы; |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Ильясов Р.М. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| 10. | Петров И.И. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәдәният бүлеге башлыгы; |
| 11. | Заһидуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| 12. | Мөхәрләмов Р.К. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы; |
| 13. | Габдрахманов И.Д. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе; |
| 14. | Габдрахманов Ф.С. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге башлыгы; |
| 15. | Хөснетдинов А.А. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы. |

2. Кушымта итеп бирелгән Федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
башлыгының
2022 елның «23» 03
94 номерлы карарына
кушымта

Федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) төзү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Муниципаль штаб (проект офисы) - инициация процессларын, паспортлар эшләүне, проектларны, өстенлекле проектларны (программаларны) гамәлгә ашыруны, проектларны, өстенлекле проектларны (программаларны), муниципаль берәмлекләрдә гамәлгә ашырыла торган федераль һәм республика программаларын мониторинглауны һәм бәяләүне хокукый, методик, мәгълүмати-технологик, оештыру-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы киңәшмә орган.

Штабны (проект офисын) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы җитәкли.

Штаб (проект офисы) үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль норматив хокукый актларга таянып эш итә.

## 2. Штабның (проект офисының) бурычлары һәм функцияләре

Штабның (проект офисының) төп бурычлары һәм функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

- өстенлекле проектны (программаны) гамәлгә ашыру буенча идарә карарларын кабул итү;
- өстенлекле проектта (программада) катнашучыларның эшчәнлеген координацияләү;
- бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм проект эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны тәэмин итү;
- муниципаль район территориясендә республика программаларын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм анализлау;
- аларның үтәлешенә үткәрелгән мониторинг нигезендә өстенлекле проект (программа) чараларын актуальләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;
- муниципаль район территориясендә республика программаларын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;

- өстенлекле проектны (программаны) актуальләштергәндә муниципаль районның җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

- үз утырышларында кергән проект (программа) тәкъдимнәрен карау;

- өстенлекле проект (программа) паспорты проектын хуплау;

- өстенлекле проектның (программаның) җыелма планын раслау, кирәк булганда аңа үзгәрешләр кертү;

- өстенлекле проектны (программаны) тормышка ашыруның барышы турында мәгълүматны карау һәм муниципаль район администрациясенең структур бүлекчәләрен һәм өстенлекле проект (программа) катнашучыларын эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә координацияләү;

- өстенлекле проектның (программаның) җыелма планының контроль нокталарын узу турында карарлар кабул итү: контроль нокталарга ирешү вакытларын күчерү, өстенлекле проектның (программаның) контроль нокталарын тәгәлләү өчен өстәмә ресурслар, катнашучылар җәлеп итү мөмкинлеген карау;

- өстенлекле проектны (программаны) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Штаб (Проект офисы) әгъзаларын тыңлау;

- өстенлекле проектны (программаны) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль районның җирле үзидарә органнары һәм муниципаль район составындагы җирлекләр, оешмалар һәм эшкуарлык бергәлеге вәкилләрен тыңлау;

- өстенлекле проектны (программаны) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар проектлары буенча карарлар кабул итү;

- өстенлекле проектны (программаны) гамәлгә ашыру турында хисапларны хуплау;

- өстенлекле проект (программа) җитәкчеләренең эшчәнлек максатларын һәм күрсәткечләрен билгеләү, аларның эшчәнлегенең файдалылыгын һәм нәтиҗәлелеген бәяләү;

- хезмәт, финанс һәм матди-техник ресурсларны планлаштыру;

- планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итү;

- нәтиҗәләргә ирешү вакытын үтәү яисә киметү;

- ресурслардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

- муниципаль районда проект эшчәнлеген оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм аның белән идарә итүне тәэмин итү;

- муниципаль районда проект эшчәнлеген оештыруга ярдәм итү;

- проект инициативаларын карау һәм проект буларак чаралар комплексын гамәлгә ашыру мөмкинлеген билгеләү;

- проектларны (проектлар портфельләрен) муниципаль реестрга кертүне тәэмин итү, паспортларны, проектларны (проектлар портфельләрен) ябу һәм кабул итү турында актларны раслау;

- проектларны (проектлар портфельләрен) гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

барлык типтагы проектлар мониторингын тәэмин итү;

- проект эшчәнлеге белән идарә итү системасын үстерү буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

- проект эшчәнлеге белән идарә итү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен контрольдә тоту;

- муниципаль районда структур бүлекчәләрнең проект офисларын төзү турында тәкъдимнәр әзерләү;

- муниципаль районда проектлы идарәгә укытуны координацияләү.

## 3. Штабның (проект офисының) хокуклары һәм вәкаләтләре

Штаб (проект офисы) түбәндәге хокукка ия:

- муниципаль районның җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль район Башкарма комитеты бүлекчәләреннән, предприятиеләрдән һәм оешмалардан Штабка (проект офисына) йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белешмәләрне һәм материалларны соратып алырга;

- билгеләнгән тәртиптә муниципаль районның пландагы һәм проекттагы эшчәнлеккә үзгәрешләр кертергә;

- проектта катнашучылар тарафыннан башкару өчен мәҗбүри булган норматив методик документлар әзерләргә;

- Штаб (проект офисы) компетенциясендәге мәсьәләләр карала торган киңәшмәләрдә һәм башка чараларда катнашырга.

## 4. Штаб (проект офисы) составы һәм аның эшен оештыру

Штаб (проект офисы) эшчәнлегенең төп формасы булып Штаб (проект офисы) утырышы тора.

Штаб (проект офисы) структурасын һәм санын, эшчәнлек шартларыннан һәм үзенчәлекләреннән чыгып, Татарстан Республикасы муниципаль районы Башлыгы раслый.

Штаб (проект офисы) составы Штаб (проект офисы) функцияләренә бәйле рәвештә формалаша.

Штаб (проект офисы) җитәкчесе (штаб җитәкчесе урынбасары):

- Штаб (проект офисы) эшен оештыра һәм контрольдә тота;

- үз компетенциясе чикләрендә Штаб (проект офисы) эшчәнлегенә кагылышлы документларны имзалый;

- Штабның (проект офисының) проектны гамәлгә ашыруда катнашучы барлык катнашучылар белән нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыра;

- Штаб (проект офисы) утырышларын әзерләүне тәэмин итә;

- Штаб (проект офисы) карарларының үтәлешен контрольдә тота;

- проект эшчәнлеген оештыруны регламентлаучы норматив хокукый актлар проектларын килештерә;

-ведомство буйсынуындагы оешмаларда проект эшчәнлеген оештыруны координацияләүне һәм аңа мониторингны тәэмин итә;

- нәтиҗәлелек күрсәткечләрен мониторинглау инструментын гамәлгә кертүне тәэмин итә;

-проектлар белән идарә итү һәм проект документлар әйләнеше процедураларын үстерүне һәм аларга ярдәм күрсәтүне оештыра;

- проект офислары һәм проект эшчәнлегенең башка катнашучылары һәм аны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча затлар белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә;

-коммуникацияләр белән идарә итү процессын җайга сала, куркынычларны (рискларны) һәм проектларны гамәлгә ашыру проблемаларын бетерүгә яисә киметүгә юнәлдерелгән чараларда катнаша;

-проект эшчәнлеген популярлаштыруны һәм проект культурасын үстерүне тәэмин итә;

-проектлар белән идарә итү (администрацияләү) эшен координацияли;

-проект эшчәнлегендә катнашучы хезмәткәрләрне кызыксындыру системасын булдыруны һәм үстерүне координацияли;

-проект эшчәнлеге өлкәсендә хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгын үстерү һәм тәҗрибә туплау буенча эшчәнлекне координацияли.

Штаб (проект офисы) әгъзалары Штаб (проект офисы) җитәкчесе тарафыннан алар арасында бүленгән вазыйфалар нигезендә Штаб (проект офисы) бурычларын һәм функцияләрен башкаралар.

Штаб (проект офисы) әгъзасының проектларны гамәлгә ашыруны алып бару юнәлеше буенча бурычлары:

- Проект эшчәнлегендә катнашучыларга проектлы идарә мәсьәләләре буенча консультация бирә;

- Проект буенча документларга мәгълүмати белешмәләр, аналитик материаллар һәм эксперт бәяләмәләре әзерли;

- проект эшчәнлеге белән идарә итүне гамәлгә кертүнең яңа процессларын раслауда (апробацияләүдә) катнаша;

- проект эшчәнлеге буенча реестрларны тулыландыра һәм аны актуаль хәлдә тота;

- Проектлар буенча документлар архивын алып баруны тәэмин итә һәм актуаль хәлдә тота.

Штаб (проект офисы) әгъзасының проектларны гамәлгә ашыру мониторингы юнәлеше буенча бурычлары:

- муниципаль район территориясендә республика программаларын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә мониторинг һәм анализ ясый;

- муниципаль район территориясендә республика программаларын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмати-аналитик материаллар әзерли;

Максатларга, күрсәткечләргә, бурычларны хәл итүгә һәм нәтиҗәләргә, контроль нокталарга һәм проект эшчәнлегенең башка элементларына мониторинг ясауны да кертеп, проектларны гамәлгә ашыру статусын даими нигездә мониторинглауны гамәлгә ашыра;

- проектларны мониторинглау кысаларында аналитик материаллар, презентацияләр һәм вакытлы хисаплылыкны әзерли;

- проектларны һәм проект эшчәнлеген гамәлгә ашыру мониторингы инструментларын үстерүдә катнаша;

- мониторинг буенча документлар архивын тулыландыра һәм актуаль хәлдә тота;

- муниципаль район Штабы (проект офисы) тарафыннан проектларга карата оештырылган контроль чараларда катнаша.

Штаб (проект офисы) әгъзасының проектлы идарә методологиясе һәм аңа өйрәтү юнәлеше буенча бурычлары:

-проектлы идарә методологиясе мәсьәләләре буенча проект эшчәнлегендә катнашучыларга консультация бирә;

-проектлы идарә методологиясен эшли, аны гамәлгә кертүне һәм актуальләштерүне тәэмин итә;

-метология буенча документлар архивын тулыландыра һәм актуаль хәлдә тота;

-проектлы идарә өлкәсендә иң яхшы тәҗрибәләрне җыюны һәм кулланышка кертүне гамәлгә ашыра;

-проект эшчәнлеге өлкәсендә һөнәри компетентлыкны үстерү эшчәнлеген координацияли;

-проект эшчәнлегендә катнашучыларга карата квалификация таләпләрен бәяләүдә катнаша;

-проект эшчәнлегендә катнашучыларны укыта.

Штаб (проект офисы) әгъзалары:

- штаб (проект офисы) утырышларында һәм карала торган мәсьәләләр турында фикер алышуда катнашалар;

- штаб (проект офисы) утырышларында докладлар белән чыгыш ясыйлар;

- Штаб (проект офисы) каравына тикшерелә торган мәсьәләләр буенча документлар һәм материаллар тәкъдим итәләр;

- Штабның (проект офисының) чираттагы утырышына тәкъдимнәр кертәләр;

- көн тәртибенә фикер алышуга мәсьәләләр кертү турында тәкъдимнәр кертәләр;

- Штаб (проект офисы) карарларын әзерләүдә һәм кабул итүдә катнашалар.

Проект офисы утырышын үткәрү турында карар җитәкче тарафыннан яисә (штаб (проект офисы) җитәкчесе күрсәтмәсе буенча) проект офисы әгъзаларының берсе тарафыннан кабул ителә.

Штаб (проект офисы) утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

Штаб (проект офисы) карарлары утырышта катнашучы Штаб (проект офисы) әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, Штаб (проект офисы) җитәкчесенең (утырышта рәислек итүче) тавышы хәлиткеч булып тора.

Штаб (проект офисы) утырышларында кабул ителгән карарлар Штаб (проект офисы) җитәкчесе тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Илкүләм проектны гамәлгә ашыру кысаларында Штабның (проект офисынын) карарлары мәҗбүри үтәлергә тиеш.